**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Алших авыл җирлегенең Теңкәш авылында гражданнар җыены карары**

19 ноябрь 2024ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Алших авыл җирлегенең Теңкәш авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2025 елда Алших авыл җирлегенең Теңкәш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тотуга;

- торак пункт территориясен төзекләндерү (кышкы чорда юлларны кардан чистарту, җәйге вакытта территорияне чабу, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү) юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Алших авыл җирлегенең Теңкәш авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Алших авыл җирлеге башлыгы _________ А.П. Андреев

Халык җыены секретаре _________ Л.Р. Сагдеева